РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
02.10.2020

**КАРАР**
№ 508

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2020 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 нче пунктлары, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында » 2015 елның 16 мартындагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, күрсәтелгән законның кушымтасында бәян ителгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2020 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы, «2020 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерциясе буенча торак урыны гомуми мәйданының 1 квадрат метры бәясе нормативы һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2020 елның 29 июнендәге 351-пр номерлы Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуаль хуҗалыгы министрлыгы приказы белән җитәкчелек итеп, һәм шулай ук “Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы” Коммерцияле булмаган партнерлык мәгълүматларына нигезләнеп, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елга найм килешүе буенча гражданнарны торак урынына мохтаҗ булуларын тану максатыннан, гражданның һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының керемен һәм аларның милкендә булган салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләргә :

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 701 481,00 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 892 794,00 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1 147 878,00 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 1 530 504,00 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 1 913 130,00 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 2 295 756,00 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 2 678 382,00 сум;

1.2. Исәп-хисап нигезендә гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 16 790,05 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 10 684,58 сум;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 9 158,21 рублей.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда Тәтеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренә әлеге карарның 1.2 пунктчасында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне кулланырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары А.Ф.Әхмәтшинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзасы яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2020 елда салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү Методикасы**

1. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алу өчен базар хакының исәпләнгән күрсәткече (алга таба-исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП Х РС х РЦ, бирелдә:

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ – Тәтеш муниципаль районында торак урыны мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый торган уртача исәп-хисап бәясе 21 257,00 сум.;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 21 257,00 х 33 = 701 481,00 сум.;

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 21 257,00 х 42= 892 794,00 сум.;

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 21 257,00 х 18 х 3 = 1 147 878,00 сум.;

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 21 257,00 х 18 х 4 = 1 530 504,00 сум.;

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 21 257,00 х 18 х 5 = 1 913 130,00 сум.;

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 21 257,00 х 18 х 6 = 2 295 756,00 сум.;

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 21 257,00 х 18 х 7 = 2 678 382,00 сум.

2. Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең иң чик күрсәткече:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$) / (0,25 х РС), бирелдә:

СЖ – исәп-хисап күрсәткече;

ПС – 1 айга кредит буенча процент ставкасы (9,4%/12);

КП - кредит срогына кредит буенча түләүләр саны (айлар саны) 26,5*12;

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен:

ПД = (0,7 х 701 481,00 х 9,4%/12) / (1 - (1 +9,4%/12) $^{-318}$) / (0,25 х 1) = 16 790,05 сум.;

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = (0,7 х 892 794,00 х 9,4%/12) / (1 - (1 +9,4%/12) $^{-318}$) / (0,25 х 2) = 10 684,58 сум.;

в) өч кешедән торган гаиләгә:

ПД = (0,7 х 1 147 878,00 х 9,4%/12) / (1 - (1 +9,4%/12) $^{-318}$) / (0,25 х 3) = 9 158,21 сум.;

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

ПД = (0,7 х 1 530 504,00 х 9,4%/12) / (1 - (1 +9,4%/12) $^{-318}$) / (0,25 х 4) = 9 158,21 сум.